Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

2020 елның 10 ноябре № 3

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мамашир авыл җирлегенең Тәмәй авылында гражданнар җыены уткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Тәмәй авылында 2020 елның 24 ноябрендә 19 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Авыл мәчете бинасында халык җыены уткәрү.Тәмәй авылы, Ленин ур., 2А.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: "2021 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан), 90 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк, 4 баласы булган һәм аннан да күбрәк балалары булган, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан тыш, 2021 елда һәр бәлигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?:

-Тәмәй авылында урамнарга вак таш җәелгән юлларны ремонтлау , авылларның урам-юл челтәрен карап тоту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Тәмәй авылында су белән тәэмин итү челтәрен һәм су скважинасы өчен будканы ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- янгын гидрантларын комплектлау өчен сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру ;

- зиратларны һәм күмү урыннарын карап тоту, җирләү кирәк-яраклары өчен склад бүлмәсе төзү, киртәләмә ясау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек;

- торак пункттан керү юлында (чыгу юлында) видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру ;

“ ӘЙЕ “ « КАРШЫ"»

3.Халык җыенын уткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) хәл итәргә кирәк.

4. Халык җыенын Мәмәшир авыл җирлеге башкарма комитеты оештыра.

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгән көннән 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Мамаширавыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　и. г. Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702